**«РАСЛЫЙМ»**

**Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры**

**_______________ Э.Н. Фәттахов**

**«30» ноябрь 2016 ел**

# ТАТАР ТЕЛЕ

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының**
**татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучыларына**
**2017 нче елда татар теленнән төп дәүләт имтиханын үткәрү**
**материалларының үзенчәлекләре**
**(спецификация)**

**Рус телендә гомуми белем бирүче оешмаларның татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучылары өчен 2017 нче елда татар теленнән төп дәүләт имтиханын үткәрү материалларының үзенчәлекләре (спецификация)**

1. **Төп дәүләт имтиханын үткәрү материалларының әһәмияте**

Төп дәүләт имтиханын үткәрү рус телендә гомуми белем бирүче оешмаларның IX сыйныфын тәмамлаучы укучыларның татар теленнән әзерлек дәрәҗәләрен бәяләүне күздә тота.

**2. Төп дәүләт имтиханын үткәрү материаллары эчтәлеген билгели торган документлар**

Төп дәүләт имтиханын үткәрү материаллары түбәндәге документка нигезләнеп эшләнә:

Харисова Ч.М., Фәтхуллова К.С., Хәбибуллина З.Н. Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11 нче сыйныфлар. – Казан: Мәгариф, 2011. – 239 б.

Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына татар теле: үрнәк гомуми программа V – 1X сыйныфлар /Төзүчеләр: Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова, Г.Р.Шакирова

// http://mon.tatarstan.ru/rus/programmy.htm?page=2

**3. Төп дәүләт имтиханын үткәрү материалларының төзелешен эшләү, эчтәлегенә мәгълүматлар сайлау**

Эш укучыларның лингвистик компетенциясен тикшерә: тел һәм сөйләм турындагы белемнәр; тел материалы белән эшләгәндә, лингвистик белемнәрне куллана алу; шулай ук тану, аеру, фикер йөртү осталыклары һәм күнекмәләре. Формалашкан тел компетенциясе дәрәҗәсе турында укучыларның тел нормаларын (лексик, грамматик, стилистик, орфографик, пунктуацион) үтәү белән бәйле осталыклары һәм күнекмәләре хәбәр итә. Коммуникатив компетенция эштә укучыларның сөйләм эшчәнлегенең нәтиҗәле һәм рецептив күнекмәләренә ия булуы дәрәҗәсе тикшерү белән ачыклана.

Төп дәүләт имтиханын үткәрү материалларындагы биремнәр тупланмасы укучыларның әзерлек дәрәҗәсен бәяләргә ярдәм итә.

Биремнәрне бәяләү системасы педагогик тикшерүләр теориясе һәм практикасы таләпләрен һәм татар телен укыту традицияләрен истә тотып эшләнде.

**4. Төп дәүләт имтиханын үткәрү материалларының төзелеше һәм эчтәлеге**

Төп дәүләт имтиханын үткәрү материалларының һәр варианты язма һәм телдән җавап бирү өлешеннән гыйбарәт. Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе тел материалының һәм тикшерелә торган күнекмәләрнең катлаулылык дәрәҗәсенә, шулай ук биремнең тибына бәйле.

Биремнәрнең чагылышы 1 нче таблицада бирелә.

*Биремнәрнең чагылышы*

*1 нче таблица.*

| Эшнең өлешләре | Биремнәрнең саны | Башлангыч (максималь) иң югары балл | Биремнәрнең төрләре (типлары) |
|---|---|---|---|
| Язма өлеше | 1 | 20 | Киңәйтелгән җавап таләп иткән бирем |
| Телдә җавап бирү өлеше | 4 | 65 | |
| **Барлыгы** | **5** | **85** | |

**5. Төп дәүләт имтиханын үткәрү материалларын эчтәлекләре һәм эш төрләренә нигезләнеп бүлү**

Язма өлешендәге 1 бүлек биремнәре - тәкъдим ителгән текст нигезендә грамматик һәм лексик берәмлекләр белән эшләү күнекмәләрен, 2 нче бүлек биреме төрле текстлар яза алу күнекмәсен тикшерә.

Телдән җавап бирү өлешендә сөйләм күнекмәләренә игътибар ителә. Әлеге бүленеш 2 нче таблицада күрсәтелгән.

*2 нче таблица*

| Бүлекләр | Биремнәр саны | Иң югары башлангыч балл | 85 баллга тигез булган иң югары башлангыч баллдан биремнәрнең әлеге кисәге өчен куела торган башлангыч балл проценты |
|---|---|---|---|
| Сөйләм. Язма сөйләмне адекват аңлау. Изложение. Бирелгән тема һәм сөйләмнең функциональ-мәгънәви төре нигезендә текст төзү. | 1 | 20 | 24 |
| Телдән җавап бирү | 4 | 65 | 76 |
| **Барлыгы** | 5 | 85 | 100 |

**Телдән җавап бирү өлешендәге биремнәрнең якынча тематикасы**

Аралашу түбәндәге якынча темаларга бәйле булачак: гаиләдә һәм мәктәптә аралашу; дуслар һәм туганнар белән аралашу; яшьләрнең мавыгулары; туган ил; күренекле кешеләр; табигать һәм экология проблемалары; сәламәт яшәү рәвеше; һөнәр сайлау.

## 6. Төп дәүләт имтиханын үткәрү материалларын катлаулылык дәрәҗәсеннән чыгып бүлү

Төп дәүләт имтиханын үткәрү материалларының катлаулылык дәрәҗәсе ягыннан бүленеше 4 нче таблицада күрсәтелгән.

*Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе буенча бүленеше*

*4 нче таблица*

| Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе | Биремнәрнең саны | Иң югары башлангыч балл | 85 баллы иң югары башлангыч баллдан чыгып, биремнәрнең әлеге кисәге өчен куелган башлангыч балл % |
|---|---|---|---|
| Нигез (база) | 2 | 26 | 30 |
| Югары | 3 | 59 | 70 |
| Барлыгы | 5 | 85 | 100 |

## 7. Эшне башкару вакыты

Төп дәүләт имтиханының язма өлешен эшләү өчен, 3 сәгать 55 минут вакыт бирелә.

Телдән җавап бирү өлешендәге биремнәрне башкару өчен, һәр укучыга 15 минут тәкъдим ителә.

## 8. Өстәмә материаллар һәм җиһазлар

Татар теле буенча төп дәүләт имтиханын үткәргәндә, орфографик сүзлектән файдаланырга рөхсәт ителә.

Телдән җавап бирү өлешендәге биремнәрне башкару өчен, аудиторияләрдә махсус программалы компьютер һәм микрофоннар булырга тиеш.

**9. Аерым биремнәрне һәм эшне тулаем бәяләү системасы**

Язма өлешнең биременең җавабы махсус эшләнгән критерийлар буенча тикшерелә. Уңышлы башкарган укучыга куела торган иң югары балл – 10.

Укучының грамоталылыгын һәм язма сөйләменең төгәллеген бәяләү сочинение элементлы изложение тикшерү нигезендә башкарыла, 10 югары балл куела.

Телдән җавап бирү өлешендәге биремнәрнең дөреслеген бердәм төп дәүләт имтиханын үткәрү буенча махсус әзерлек узган татар теле белгечләре тикшерә.

**10. Төп дәүләт имтиханын үткәрү шартлары (белгечләргә таләпләр)**

Татар теленнән төп дәүләт имтиханы махсус пунктларда уздырыла. Әлеге пунктлар гомуми белем бирү учреждениеләре базасында оештырыла.

Татар теленнән төп дәүләт имтиханы үткәрелә торган аудиториягә филолог белгечләр кертелми. Имтиханны татар теле һәм әдәбиятын укытмый торган педагог уздырырга тиеш.

Алга таба имтихан үткәрүнең тәкъдим ителгән тәртибе. Имтихан үткәрүнең **тәкъдим ителә торган тәртибе** түбәндәгечә.

Имтихан материаллары салынган пакетны алгач, укучы биремнәрне үтәячәк барлык бланкларга имзасын куя. Имза куелган бланклар укучының эш өстәлендә кирәкле тәртиптә урнаштырыла һәм эш барышында тотырыла.

**11. 2016 нчы ел белән чагыштырганда 2017 нче елгы үзгәрешләр**

Гомумән эшнең төп характеристикалары саклаган. Телдән җавап бирү өлеше өстәлгән.

**12. 2017 нче елгы бердәм республика тестын үткәрү материаллары планы**

2017 нче елда татар теленнән бердәм республика тестын үткәрүнең эчтәлеге Кушымтада китерелгән гомумиләштерелгән планда чагыла.

*Кушымта*

**2017 елда татар теленнән бердәм республика тестын үткәрү материалларының гомумиләштерелгән планы**

*Эштә һәм җавап бланкларында биремнәрне билгеләү: А - җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәр, В - кыска җавап бирүне таләп иткән биремнәр, С - укылган текст нигезендә үз фикерен белдерә алуын тикшерүгә юнәлдерелгән ачык типтагы биремнәр.*

*Биремнәрнең авырлык дәрәҗәсе: Н – нигез (база), Ю – югары.*

| № | Биремнең эштәге билгеләнеше | Эчтәлекнең тикшерелә торган элементлары | Эчтәлекнең тикшерелә торган элементларының коды | Тикшерелә торган күнекмәләр коды | Биремнәрнең авырлык дәрәҗәсе | Эшләнгән бирем өчен куелган иң югары балл | Биремне үтәү вакыты (мин.) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **ЯЗМА ӨЛЕШЕ** | | | | | | | |
| 1 | 1 | Төрле стильдәге һәм жанрдагы текстларны тикшерү. Татар әдәби теленең байлыгы һәм тәэсирле булуы. Аерымланган кисәкләр янында тыныш билгеләре. Эндәш һәм кереш сүзләр янында тыныш билгеләре. Тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре. Төрле стильдәге һәм сөйләм төрендәге текстлар төзү. | 6<br>5.1<br>4.5<br>4.4<br>4.3<br>5.3 | 13<br>10.2<br>11<br>17<br>19<br>20<br>21 | Ю | 20 | 235 |
| **ТЕЛДӘН ҖАВАП БИРҮ ӨЛЕШЕ** | | | | | | | |
| 2 | 1 | Текстны кычкырып уку | 2.1.1<br>2.1.2 | 2<br>12 | Н | 12 | 4 |
| 3 | 2 | Шартлы сораштыруда катнашу | 1.1.1<br>2.1.1<br>2.1.2 | 1<br>2<br>3<br>4<br>5<br>12 | Ю | 25 | 3 |
| 4 | 3 | Рәсемне тасвирлау | 1.1.1<br>2.1.1<br>2.1.2 | 1<br>2<br>3<br>4<br>5<br>12 | Н | 14 | 4 |
| 5 | 4 | Монологик сөйләм | 1.1.1<br>2.1.1<br>2.1.2 | 1<br>2<br>3 | Ю | 14 | 4 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 4<br>5<br>12 | | | | |

Барлык бирем – 5, шуларның катлаулылык дәрәҗәсе буенча: Н – 2, Ю -3
Беренчел башлангыч балл – 88
Эшне башкару вакыты – 250 мин.